**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чемодурово авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чемодурово авылы № 11 «12» декабря 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 маендагы 94 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган 08.10.2018 №108, от 26.11.2018 №116, от 24.10.2022 №59), от 14.03.2023 №73, от 11.06.2024 №114, 15.10.2024 №124, 10.06.2025 №143карарлар редакциясендә) Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләрне кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турындагы 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Чемодурово авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 маендагы 94 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карары белән расланган 08.10.2018 №108, от 26.11.2018 №116, от 24.10.2022 №59), от 14.03.2023 №73, от 11.06.2024 №114, 15.10.2024 №124, 10.06.2025 №143карарлар редакциясендә) Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими

нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлегенең 1.5 пунктында «15389,00» саннарын «16928,00»саннарына алмаштырырга.

1.2. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.П.Курганская

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советы карарына кушымта
«12» декабря 2025 № 11

Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге башлыгы, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларның айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Авыл җирлекләрендә |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23201 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 16931 |
| Депутат | 16928 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 16928 |